| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.12.2021 № 693-пр

Казан ш.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 08.11.2021 № 630-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт вазифаларын башкару өчен зарури профессиональ белем, белгечлек һәм әзерлек юнәлеше дәрәҗәсенә квалификацион таләпләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79–ФЗ Федераль законның 12 статьясының 1 кисәгенә, «Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы 1 кисәгенә туры китереп, б о е р а м:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт вазифаларын башкару өчен зарури профессиональ белем, белгечлек һәм әзерлек юнәлеше дәрәҗәсенә квалификацион таләпләрне раслау турында” 08.11.2021 № 630-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан

Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт вазифаларын башкару өчен зарури профессиональ белем, белгечлек һәм әзерлек юнәлеше дәрәҗәсенә квалификацион таләпләренең 48 юлын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«

| | | |
|---|---|---|
| 48 | Әйдәп баручы белгеч | «Дәүләти һәм муниципаль идарә», «Персонал белән идарә», «Документлар эшен һәм архив эшен алып бару», «Икътисад», «Юриспруденция», «Тарих», «Инженерлык эше, технологияләр һәм техник фәннәр», «Промышленность һәм гражданнар төзелеше» белгечлеге буенча югары белем яки Россия Федерациясенең мәгариф турында законнары буенча тиешле белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләрендә тиешлеге билгеләнгән исемлекләрдә китерелгән башка белгечлекләр яки әзерлек юнәлешләре |

».

Министр Ф.Ә.Әһлиуллин